СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**30 сентябрь 2016 ел** **№ 23**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризаме, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Чернобыль АЭСындагы аварияне бетерүдә катнашучылардан, 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән тыш, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - вак таш.:<br>Иске Кырлай авылы Һади Такташ урамындагы 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр<br>Иске Иябаш авылы Муса Җәлил урамы, 46нчы йорттан 47нче йортка кадәр<br>Өтнә авылы Салих Сәйдәшев урамындагы 15 нче йорттан 16 нчы йортка кадәр<br>Югары Әзәк авылы 8-нче | 43700 сум<br>5400сум<br>13600сум<br>16900 сум |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | йорттан Мәктәп урамы буенча 10-нчы йортка кадәр Түбән Мәтәскә авылы Тукай урамы буенча 14,14 а йортыннан; Түбән урамы буенча 1,2-нче номерлы йорттан; Киров урамындагы 7 нче йорттан 15 нче йортка кадәр; Мәктәп урамы буенча 4,11,15 номерлы йорт; Тынычлык урамындагы 6-нчы йорттан 11-нче йортка кадәр; Югары Мәтәскә авылы Дуслык урамы буенча 1 нче йорттан 4 нче йортка кадәр; Тукай урамы буенча 2,4,6 нчы йорттан; Тукай урамы буенча 9,11,15 номерлы йорт; Яшьләр урамы буенча 1 нче йорттан Мөндеш авылы Чишмә урамындагы 33нче йорттан 39нчы йортка кадәр; Чишмә урамындагы 5 нче йорттан 9 нчы йортка кадәр; Татарстан урамындагы 25нче йорттан 28нче йортка кадәр Казиле авылы 11-нче йорттан Җиңү урамы буенча 14-нче йортка кадәр | 70600сум<br>39600сум<br>63600сум<br>19600сум |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | - Иске Иябаш авылында коймалар урнаштыру (120м) һәм зиратларны тоту | 24000сум |
| | БАРЛЫГЫ | | 297000сум |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк ур., 12А йорт.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ